**Исполнительный комитет Алешкин-Саплыкского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Башкарма комитеты**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail: AlSap.Drz@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Алешкин-Саплык

08 декабря 2022 года №25

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарына һәм ысулларына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 26.03.2018 №4 карарына үзгәреш кертергә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Торак пунктларның гомуми файдаланудагы җирләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территорияләрендә урнашкан шәхси йорт хуҗалыклары территорияләрендә махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннардан тыш ризык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки эшләнмәләр яндыру тыела.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

Чүпрәле районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Башлыгы: П.Н.Артемьев